ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**28.12.2022**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 3592**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 02 ноябрендәге 2748 номерлы карары белән расланган Зеленодольск муниципаль районы яшьләр сәясәте муниципаль оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 20 июнендәге 587 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарын, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районы муниципаль оешмалары хезмәткәрләренә түләү шартлары турында» 2021 елның 02 ноябрендәге 2748 номерлы карары белән (Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 25 гыйнварындагы 123 номерлы, 2022 елның 04 апрелендәге 1016 номерлы карарларына кертелгән үзгәрешләр белән) расланган, Зеленодольск муниципаль районы яшьләр сәясәте муниципаль оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмәгә кушымта нигезендә, үзгәрешләр кертергә.
2. Учреждение җитәкчеләренә үз локаль актларын әлеге карарга туры китерергә.
3. Әлеге карарны Зеленодольск муниципаль район Советы Аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә буенча бүлегенә «Интернет» челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru ) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр составындагы Зеленодольск муниципаль районы рәсми порталында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru ) урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы А.В.Старостин

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты 2022 елның 28 декабрендәге 3592 номерлы карарына кушымта

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районы яшьләр сәясәте муниципаль оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2021 елның 02 декабрендәге 2748 номерлы карары белән расланган Зеленодольск муниципаль районы яшьләр сәясәте муниципаль оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында нигезләмәдәге үзгәрешләр:

1.1. VIII бүлекнең 5 һәм 6 пунктларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"5. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр яшьләр сәясәте муниципаль оешмалары җитәкчесенә, эшчәнлекнең эффективлык критерийлары нигезендә билгеләнгән эшчәнлек нәтиҗәләрен исәпкә алып, яшьләр сәясәте муниципаль оешмаларын гамәлгә куючы тарафыннан билгеләнә.

Яшьләр сәясәте оешмасы җитәкчесенә стимуллаштыру характерындагы түләүләр ай саен, квартал саен, бер ел эшләү нәтиҗәләре буенча, мөһим һәм аеруча мөһим биремнәрне үтәгән өчен гамәлгә ашырылырга мөмкин.

6. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен яшьләр сәясәте муниципаль оешмасының җитәкче урынбасарларына, баш бухгалтерына стимуллаштыру характерындагы түләүләр, аларның эшчәнлегенең эффективлык критерийлары нигезендә билгеләнгән эшчәнлек нәтиҗәләрен исәпкә алып., яшьләр сәясәте муниципаль оешмасы җитәкчесе тарафыннан билгеләнә. Җитәкче урынбасарларына, баш бухгалтерга стимуллаштыру характерындагы түләүләр ай саен, квартал саен, ел йомгаклары буенча, мөһим һәм аеруча мөһим биремнәрне үтәү өчен гамәлгә ашырылырга мөмкин".